КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 октябрь г.Казань № 1264

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә җиңүчеләр өчен махсус дәүләт стипендияләре турында» 2006 ел, 14 август, 414 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә җиңүчеләр өчен махсус дәүләт стипендияләре турында» 2006 ел, 14 август, 414 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 декабрь, 935 нче, 2017 ел, 15 ноябрь, 878 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә җиңүчеләр өчен махсус дәүләт стипендияләре түләү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин